ҖОМГА
12
ФЕВРАЛЬ
1943 ел.
№ 35 (6757)
Аерым номеры 20 тиен.

БАРЛЫК ИЛЛӘРНЕҢ ПРОЛЕТАРИЙЛАРЫ, БЕРЛӘШЕГЕЗ!

КЫЗЫЛ ТАТАРСТАН

ВКП(б) ның ТАТАРСТАН ӨЛКӘ ҺӘМ КАЗАН ШӘҺӘР КОМИТЕТЛАРЫ, ТАССР ВЕРХОВНЫЙ СОВЕТЫ ҺӘМ ХЕЗМӘТ ИЯЛӘРЕ ДЕПУТАТЛАРЫНЫҢ КАЗАН ШӘҺӘР СОВЕТЫ ОРГАНЫ.

ПАРТКАБИНЕТЛАРНЫҢ ЭШЛӘРЕН ЯҢА ТАЛӘПЛӘР ЮГАРЫЛЫГЫНА

Илебезнең күп миллионлы кадрлары социалистик төзелешнең төрле тармакларында дөрес җитәкчелек итсеннәр өчен, эчке һәм тышкы обстановканы дөрес аңласыннар өчен алар марксизм-ленинизм теориясе белән коралланган булырга тиешләр.

Партия кабинетлары бу бурычларны үтәүдә, кадрларның идея-политик белем дәрәҗәләрен күтәрүдә гаять зур роль уйныйлар. Шуның белән бергә, парткабинет работникларына хезмәт ияләре арасында политик-масса эшен җәелдерү бурычы да йөкләнә.

Ватан сугышы фронтына киткән иптәшләр урынына яңа кадрлар күтәрелделәр. Без аларны пропагандистлар, агитаторлар, башлангыч партоешма секретарьлары һ. б. постында күрәбез. Аларның теоретик һәм экономик белем дәрәҗәләрен күтәрүдә парткабинетлардан җитди эш таләп ителә.

ВКП(б) Үзәк Комитетының «ВКП(б) тарихының кыскача курсы» басылып чыгу уңае белән чыгарган карарларыннан һәм аннан соңгы күрсәтмәләреннән соң, байтак кына парткабинетлар үзләренең эшләрен яңа баштан кордылар. Мондый парткабинетлар безнең республикабызда да аз түгел. Бөгелмә, Алабуга районнары һәм Казанның Киров, Бауман район парткабинетлары әнә шундыйлар рәтенә керәләр. Бу парткабинетлар үзләренең эшләрен чыннан да хәзерге таләпләр югарылыгында оештырдылар. Алар кадрларга марксизм-ленинизм теориясен үзләштерүдә практик ярдәм күрсәтәләр. Алдынгы агитколлективларның, пропагандистларның тәҗрибәләрен популярлаштыралар. Лекторлар, пропагандистлар, агитколлектив җитәкчеләре ВКП(б) тарихын үзлегеннән өйрәнүчеләр белән семинарлар, консультацияләр, киңәшмәләр үткәрәләр, аларга методик яктан булышлык күрсәтәләр. Бу эшкә әзерлекле һәм югары квалификацияле работникларны тарталар. Шулай ук бу парткабинетлар активның экономик һәм хәрби белем дәрәҗәсен күтәрүгә дә зур әһәмият бирәләр.

Аларда бөек ватан сугышына багышланган күргәзмәләр оештырылган. Ул күргәзмәләр киң массаны тирән патриотик рух белән тәрбияләүдә гаять зур роль уйныйлар.

Ләкин республикабыздагы барлык парткабинетлар да шулай үрнәкле эшлиләр дип әйтеп булмый әле. Үзләренең эшләрен хәзерге таләпләргә яраклаштырып үзгәртеп кормаган парткабинетлар да бар. Менә Питрәч, Тәмте һәм Бондюг районнарын алыйк. Бу районнардагы парткабинетларда активның политик һәм экономик белемен күтәрүгә әһәмият бирелми. Лекторлар, агитаторлар, пропагандистлар белән, ВКП(б) тарихын үзлегеннән өйрәнүчеләр белән тиешле эш алып барылмый. Парткабинет мөдирләре Урайская, Федорова һәм Вәлиев иптәшләр үзләренең эшләренә җавапсыз карыйлар. Ә ВКП(б) ның Тәмте, Бондюг, Питрәч райкомнары исә алардан эш таләп итмиләр, димәк, парткабинетларның эшенә җитәкчелек итмиләр. Героик совет халкының бөек ватан сугышы шартларында мондый җавапсызлыкка, эшлексезлеккә һич тә түзеп торырга мөмкин түгел.

Парткабинет работниклары эшчеләр, колхозчылар массасы белән ныклы элемтәдә булырга, предприятиеләрдә, колхозларда, совхозларда докладлар, беседалар, лекцияләр оештырырга һәм ВКП(б) тарихын үзлекләреннән өйрәнүче иптәшләргә практик ярдәм оештырырга тиешләр.

Парткабинетлар алдына куелган бурыч гаять зур. Алар марксизм-ленинизм теориясе белән кораллануда, экономик һәм хуҗалык мәсьәләләрен үзләштерүдә активка ныклы ярдәм итсеннәр, киң масса арасында политик-тәрбия эшләрен җәелдерүдә, социалистик ярышны оештыруда, политик һәм хуҗалык бурычларны үтәүдә партия оешмаларына ярдәм итүче сугышчан үзәк булып әверелсеннәр.

Партия кабинетларының эшендә төп игътибар лекторларга, докладчыларга, пропагандистларга, политик агарту работникларына, агитколлектив җитәкчеләренә, партия тарихын, хәзерге заманның хәрби-политик һәм халыкара обстановкасын үзлекләреннән өйрәнүчеләргә көндәлек ярдәм оештыруга юнәлдерелгән булырга тиеш.

СОҢГЫ СӘГАТЬТӘ

БЕЗНЕҢ ГАСКӘРЛӘР ЛОЗОВАЯ ШӘҺӘРЕН АЛДЫЛАР

11 нче февральдә Украинада безнең гаскәрләр, кискен атака нәтиҗәсендә, ЛОЗОВАЯ шәһәрен һәм тимер юл узелын алдылар. Шәһәргә беренче булып генерал-майор иптәш И. Я. КУЛАГИН частьлары бәреп керделәр. Трофейлар кулга төшерелде.

СОВЕТ ИНФОРМБЮРОСЫ.

Москва, Кремль, иптәш И. В. СТАЛИНГА

Кадерле Иосиф Виссарионович!

Сталинград һәм Воронеж янында, Донда һәм Төньяк Кавказда безнең батыр Кызыл Армиябезнең уңышлы һөҗүме һәм данлыклы җиңүләре, немец-фашист оккупантларның күп санлы дивизияләрен һәм полкларын тар-мар итү үзенең саклык акчаларын танклар, самолетлар һәм башка кораллар төзелешенә дәүләткә бирүче совет халкы арасында әлегәчә күрелмәгән патриотизм күтәрелеше тудырдылар.

Кызыл Армиянең данлыклы хәрби уңышларына эшчеләр һәм эшче хатын-кызлар, инженерлар, техниклар һәм хезмәткәрләр фронтка көннән-көн күбрәк санда кораллар һәм сугыш припаслары биреп, фабрикаларда һәм заводларда хезмәт батырлыклары белән җавап бирәләр.

Тылның һәм фронтның бердәмлеге тагын да ныгыды, Кызыл Армиянең халык белән элемтәсе тагын да көчәйде.

Фронт һәм тыл үзләренең героик эшләрендә бердәм максат белән, бердәм омтылыш белән—«немец оккупантларны тар-мар итү һәм аларны ватаныбыз чикләреннән куу өчен алга!» дигән Сезнең чакыруыгызны үтәү омтылышы белән рухландылар.

Профессиональ союзларның Бөтенсоюз Үзәк Советы һәм Профсоюзларның Үзәк комитетлары, Кызыл Армиягә сугышчан ярдәмне тагын да күбрәк көчәйтергә һәм, шулай итеп, явыз дошманны җиңүебез сәгатен якынайтырга чын күңелдән омтылу белән рухланып, профсоюз суммаларыннан дәүләткә 100 миллион сум акча тапшыралар һәм бу акчаларга авиация берләшмәләре, танклар колонналары төзүне һәм аларга иптәш Сталин исемен бирүне үтенәләр.

Профсоюз суммаларына ясалган самолетлар һәм танклар тылның фронт белән элемтәсен тагын да ныгытсыннар.

Безнең сталинчы лачыннарыбыз—очучыларыбыз һәм сугышчан танкистларыбыз, безнең дәһшәтле артиллеристларыбыз һәм данлыклы пехотачыларыбыз, пулеметчикларыбыз һәм минометчикларыбыз дошманны рәхимсез җимерсеннәр һәм юк итсеннәр, туган җиребез чикләреннән немец оккупантларны кусыннар.

Профессионал союзларның Бөтенсоюз Үзәк Советы һәм профсоюзларның үзәк комитетлары Сезне, иптәш Сталин, бөек ватан сугышының беренче көннәреннән үк үзләренең бөтен эшләрен совет ватанын саклауга, явыз дошманны тар-мар итү эшенә юнәлдергән профсоюзларның киләчәктә дә эшчеләрне һәм хезмәткәрләрне фронтка барлык чаралар белән ярдәм итүгә, дәүләт планнарын һәм бөтенсоюз социалистик ярышында үз өсләренә алган йөкләмәләрен үтәүгә һәм арттырып үтәүгә оештырачакларына, эшчеләрнең, хезмәткәрләрнең һәм батыр Кызыл Армия сугышчылары, командирлары һәм политработниклары семьяларының көндәлек культура-көнкүреш ихтыяҗларын канәгатьләндерү турында кайгыртачакларына ышандыралар.

Сезнең, бөек юлбашчыбыз һәм полководецыбыз, зирәк җитәкчелегегездә Советлар Союзының кораллы көчләренең немец оккупантларны тар-мар итүләре, аларны ватаныбыз чикләреннән куулары, гитлерчы тираннарның ерткыч тырнакларына эләккән совет кешеләрен коллыктан һәм изелүдән коткарачаклары, аларны азатлыкка һәм кешеләрчә яшәүгә кайтарачаклары, ә азат ителгән совет шәһәрләре һәм авыллары өстендә советның Кызыл байраклары—социалистик ватаныбызның азатлыгы, намусы һәм бәйсезлеге байраклары җиңүле төстә җилфердәячәк сәгатьнең ерак түгеллегенә профсоюзлар тирәнтен ышаналар.

Кадерле остазыбыз һәм дусыбыз, Профессиональ Союзларның Бөтенсоюз Үзәк Советы һәм илебездәге барлык профсоюз оешмалары исеменнән кайнар сәламебезне һәм озак еллар яшәү һәм сәламәтлек теләвебезне кабул итегез.

Профессиональ Союзларның Бөтенсоюз Үзәк Советы һәм профсоюзларның Үзәк комитетлары тапшыруы буенча:

ВЦСПС секретарьлары **Н. Шверник, К. Николаева, С. Брегман.**

Профсоюзларның Үзәк Комитетлары председательләре:
К. Агаджанов, Б. Аксенов, К. Алексеев, И. Антипов, А. Асланов, Ю. Биляева, П. Борисов, Е. Баженин, А. Вассерман, Р. Гранкин, М. Гуртовой, А. Данилов, Л. Джорджишвили, М. Засорин, Ф. Захар-Невский, И. Иванов, Мария Каганович, Я. Качан, Г. Кашинцев, С. Котляр, А. Лакин, Е. Леонтьев, И. Максимов, А. Малькова, Л. Марков, С. Мешакин, В. Минин, А. Никитина, Г. Новожилов, А. Петрухин, Е. Савков, Б. Седунов, М. Симонженкова, Н. Склизков, М. Степанов, М. Тарасов, И. Шмарин.

Профессиональ союзларның Бөтенсоюз Үзәк Советы секретарьлары Шверник, Николаева, Брегман иптәшләргә

Профсоюзларның үзәк комитетлары председательләре Агаджанов, Аксенов, Алексеев, Антипов, Асланов, Беляева, Борисов, Баженин, Вассерман, Гранкин, Гуртовой, Данилов, Джорджишвили, Засорин, Захар-Невский, Иванов, Мария Каганович, Качан, Кашинцев, Котляр, Лакин, Леонтьев, Максимов, Малькова, Марков, Мешакин, Минин, Никитина, Новожилов, Петрухин, Савков, Седунов, Симонженкова, Склизков, Степанов, Тарасов, Шмарин иптәшләргә

Авиация берләшмәләре һәм танклар колонналары төзелеше өчен ССР Союзы фондына профсоюз суммаларыннан 100 миллион сум акча керткән Бөтенсоюз Профсоюзлар Үзәк Советына һәм профсоюзларның үзәк комитетларына минем туганлык сәламемне һәм Кызыл Армиянең рәхмәтен тапшыруыгызны үтенәм.

И. СТАЛИН.

Н-ЧЕ АРМИЯ
ИПТӘШ ЛОПАТИНГА
ИПТӘШ ЧЕРЕШНЮККА
ИПТӘШ РЮМИНГА

Кызыл Армия өчен кораллар төзүгә 3 миллион сум акча җыйган Н-че армиянең сугышчыларына, командирларына һәм политработникларына минем сугышчан сәламемне һәм Кызыл Армиянең рәхмәтен тапшырыгыз.

И. СТАЛИН.

Н-ЧЕ ФРОНТ
ИПТӘШ А. РОДИМЦЕВКА
ИПТӘШ М. ВАВИЛОВКА

62 нче армия исемендәге танклар колоннасы төзүгә 1.200.000 сум акча җыйган сезнең часть гвардеецларының данлыклы личный составына минем сугышчан сәламемне һәм Кызыл Армиянең рәхмәтен тапшырыгыз.

И. СТАЛИН

СОВЕТ ИНФОРМБЮРОСЫННАН

11 нче ФЕВРАЛЬДӘГЕ ИРТӘНГЕ БЕЛДЕРУ

11 нче февральгә каршы төндә безнең гаскәрләр элекке юнәлешләрдә һөҗүм сугышлары алып бардылар.

* * *

Ростов-Дон районында безнең гаскәрләр, дошманның каршылык күрсәтүен җиңеп, алга киттеләр. Икенче бер участокта немецлар контратакага, танклар һәм артиллерия белән берлектә, ике пехота полкы җибәрделәр. Н-че берләшмә сугышчылары гитлерчыларның контратакасын кире кайтардылар һәм дошманның көчле итеп ныгытылган күп кенә позицияләрен алдылар.

* * *

Краматорская районында безнең гаскәрләр һөҗүм сугышлары алып бардылар. Н-че берләшмә частьлары дошман пехотасының һәм танкларының өч контратакасын кире кайтардылар, алга киттеләр һәм халык яши торган берничә пунктны алдылар. Сугыш кырында дошманның йөзләрчә үле гәүдәләре калды. Икенче бер участокта безнең танкка каршы артиллериябез һәм бронебойщикларыбыз уты белән немецларның 11 танкысы зарарланды һәм яндырылды.

* * *

Белгород районында безнең гаскәрләр уңышлы рәвештә алга бардылар һәм халык яши торган күп кенә пунктларны алдылар. Н-че часть сугышчылары 7 орудие, 19 пулемет һәм сугыш припаслары төялгән 12 автомашина кулга төшерделәр.

* * *

Курскидан көньяктарак совет танкистлары гитлерчыларның берничә подразделениесен юк иттеләр. Өлкән лейтенант Вахмистров, йөртүче өлкән механик Манаков, радист Скуднов һәм артиллерист Кузнһов иптәшләр составындагы танк экипажы, тулы ход белән барып, немецлар колоннасына кисеп керде. Танкистлар, ут ачып һәм танк белән таптатып, бер ротадан артык немецлар пехотасын кырып ташладылар. Танкка каршы ата торган 18 орудиене һәм сугыш йөкләре төялгән 100 гә якын повозканы юк иттеләр.

* * *

Поныри районында безнең гаскәрләр сугышларның ике көне эчендә дошманның 14 орудиесен, 2 танкеткасын, 9 минометын, 22 пулеметын һәм башка трофейлар кулга төшерделәр. Н-че часть алга таба барып, 600 гә якын немец солдатларын һәм офицерларын юк итте. Тягачлары белән берлектә 4 зенит орудиесе, 50.000 патрон, йөк төялгән 60 повозка һәм башка төрле сугыш милекләре кулга төшерелде.

* * *

Украинаның бер районында хәрәкәт итүче партизаннар отряды бер район үзәгендә урнашкан немецлар гарнизонына төнлә һөҗүм ясаган. Совет патриотлары берничә дистә гитлерчыны кырып ташлаганнар һәм немец-фашист оккупантларның 2 складын яндырганнар.

Украина партизаннарының икенче бер отряды немецларның бер гарнизонын тармар иткән һәм гитлерчылар тарафыннан крестьяннардан талап алынган ашлык тутырылган берничә склад кулга төшергән, 700 тонна ашлыкны партизаннар халыкка өләшеп биргәннәр.

* * *

Югославия патриотлары немец-итальян оккупантларга каршы бик каты сугышлар алып баралар. Теслич якынында партизаннар дошманның барлык атакаларын кире кайтарганнар. Дрвент янында патриотлар бер миномет, 5 пулемет, 22 мең патрон һәм башка төрле күп сугыш милекләре кулга төшергәннәр. Врполь районында бер группа партизаннар немецларның 4 танкысын шартлатканнар һәм 50 дән артык гитлерчыны кырып ташлаганнар. Словениядә партизаннар дошманның ныгытылган бер пунктын алганнар һәм анда булган итальяннар гарнизонын бөтенләй кырып бетергәннәр.

Кызыл Армиягә монгол халкының яңа бүләге. Монголия Халык Республикасының делегациясе монгол халкы тарафыннан җыелган средстволарга төзелгән танклар колоннасын Н-че частька тапшырды. Рәсемдә: танклар колоннасының гомуми күренеше.

ТАСС фотохроникасы.

КЫЗЫЛ АРМИЯГӘ—СУГЫШ МАШИНАЛАРЫ!

„Яңа юл“ колхозы членнары 200 мең сум бирделәр

Минзәлә районындагы «Яңа юл» колхозы членнары бөек юлбашчыбызның котлау телеграммасына җавап итеп самолетлар эскадрильясы төзү фондына акча җыюны яңа дәрт белән җәелдереп җибәрделәр. Колхозның алдынгы члены иптәш Гатауллин бу хәрәкәткә беренче булып кушылды һәм үзенең саклык акчаларыннан 30 мең сумын самолетлар эскадрильясы төзү фондына биреп, патриотлыкның гүзәл үрнәген күрсәтте.

Үзенең 4 улын Кызыл Армия сафына озаткан карт колхозчы, ферма мөдире иптәш Шәрипов бу фондка 20 мең сум, Бәһаветдинов һәм Гыйлаҗов иптәшләр 15 әр мең сум, үзенең 4 улын һәм бер кызын Кызыл Армия сафына озаткан карт колхозчы иптәш Хәмидуллин 10 мең сум акча бирделәр. Колхоз председателе Абзалов Нури үзе 20 мең сум бирде.

Бу колхозда кыска гына вакыт эчендә самолетлар эскадрильясы төзү фондына 200 мең сум акча җыелды.

— Безнең саклык акчаларыбыз дошманга үлем яудыра торган самолетларга әверелеп, фашистик этләрне җир йөзеннән мәңгегә юк итсеннәр,—диләр «Яңа юл» колхозы членнары.

З. ГЫЙЗЗӘТУЛЛИНА.

ШТЫК СУГЫШЫ

ХӘРӘКӘТТӘГЕ АРМИЯ. (ТАСС ның махсус хәбәрчесеннән). Немецлар оборонасының алгы кырыен безнең артиллерия бомбага тотты. Орудиеләрнең залп тавышлары тыну белән: «Атакага әзерләнергә» дигән команда бирелде. Тиздән «Ура» тавышы яңгырады. Безнең бер группа разведчиклар кулларына винтовкалар һәм автоматлар тоткан хәлдә алга ташландылар һәм немецларның траншеяларына бәреп керделәр. Штык һәм кул сугышы башланып китте. Совет сугышчылары, дошман солдатларын мылтыктан һәм автоматтан атып, штыклар белән кадап, прикладлар белән бәреп кырдылар. Разведчиклар көчле омтылыш һәм кыюлык белән хәрәкәт иттеләр. Кызылармеец Герасимов беренче булып фашист ерткычларның оясына бәреп керде һәм 5 ен штык белән кадап ташлады.

Сугыш барышында разведчиклар бер-берсенә булыштылар. Ике немецны штык белән кадап ташлаган кызылармеец Плотниковка дошманның бер солдаты пычак күтәреп каршы ташланды. Кызылармеец Герасимов приклад белән фашистның пычагын бәреп төшерде. Коралсызландырылган гитлерчы плен алынды.

Кызылармеецлардан Алексеев, Данилов, Школьников һәм Репе немецлар урнашкан бер йортны чолгап алдылар. Алар гранаталар ыргытып һәм штыклар белән кадап, бу йорттагы фашистларны кырып бетерделәр.

Сугыш тагын да кыза төште. Разведчиклар гранаталарны һәм патроннарны атып бетерделәр. Бу сугышта безнең разведчиклар 150 немецны кырып ташладылар.

УКУЧЫЛАРНЫҢ АКТИВЛЫГЫ

Батыр сугышчыларга сугыш машиналары төзү өчен Казан шәһәре мәктәпләрендә средстволар туплау уңышлы бара.

Молотов районы мәктәпләрендә укучылар сугыш самолетлары төзү фондына кыска вакыт эчендә 160 мең сум акча туплап тапшырдылар. 19 нчы номерлы урта мәктәпнең укытучылары һәм укучылары 40 мең сум бүләк иттеләр.

189 мең 250 сум җыелды

Вахитов исемендәге Жиркомбинат эшчеләре һәм хезмәткәрләре кызылармеецларга бүләкләр җибәрү һәм эскадрилья төзү өчен 189 мең 250 сум акча җыйдылар. Акча җыю дәвам итә.

БҮРЕКЧЕЛӘР

«Кызыл бүрекче» артеле үзенең җылы бүрекләре белән хезмәт иярәре арасында яхшы танылган артельләрдән санала. Немец басып алучыларга каршы сугыш фронтларында да аның турында еш кына сүз кузгаталар икән. Күптән түгел фронттан кайткан Мортаза иптәш Камалов бу турыда түбәндәгеләрне сөйли:

— Безнең артельнең исемен мәңге исендә тотарга һәм андагы эшчеләргә гомер буе рәхмәт әйтергә сүз бирде сугышчы иптәш Корольков. Иң көчле салкында өч тәүлек буена кырда яттым мин,—ди ул.— Әгәр дә башымда колакчын җылы бүрегем булмаса, һичшиксез, каты чир алган булыр идем.

Минем «Кызыл бүрекче» артеленнән икәнемне белгәч тә:

— Әгәр дә гомерең булып анда кайтсаң, артель эшчеләренә миннән рәхмәт әйт,—дип аркамнан сөеп куйды ул.

Чыннан да, бу артельнең эшчеләре рәхмәтләрне һәм мактауларны хаклы рәвештә кабул итәрлек итеп, намус белән эшлиләр. Алар барысы да продукцияне югары сыйфатлы итеп, күбрәк эшләп чыгару өчен, шулай итеп фронтовикларны һәм тылдагы хезмәт ияләрен бүрекләр, туннар, телогрейкалар белән мул рәвештә тәэмин итү өчен көрәшәләр.

Менә өс киемнәре тегү цехы. Нурый бабай Баһаветдинов бу цехта инде 12 нче елын эшли. Ап-ак чәч-сакаллы 70 яшьләр чамасындагы бу картның бай тәҗрибәләре нигезендәге тырыш хезмәте бик күп яшьләргә үрнәк булырлык.

— Норманы күпмегә үтәп була, бабай?

Бу сораута ул, эшеннән туктамыйча гына, күзлек аша карап:

— Кичә 250 процентка үтәгән идем, ә бүген 300 гә үтәргә иде теләк, энекәш...—дип җавап кайтарды.

— Талчыктырмыймы соң?

— Мин инде шушы машинам белән 12 нче елымны эшлим. Машинаның көен белгәндә, чималда өзеклек булмаганда, хезмәт үзе бер төрле рәхәтлек биргән кебек тоела, энем...

Без Нурый бабай белән шулай сөйләшеп торганда, цехның аргы башыннан, машиналар хорына кушылып, йөрәкләрне иркәли торган матур җыр ишетелде:

Ал чәчәкләргә төрелә
Җәен болыннарыбыз,
Дошманнарны тар-мар итеп
Кайтыр былбылларыбыз...

— Ишетәсеңме, безнең батыр кызлар нинди дәрт белән эшлиләр... Син, талчыкмыйсыңмы, дип сорыйсың. Мондый күңеллелектә эшләп нинди талчыгу булсын ди, энекәш,—дип, Нурый бабай эшен дәвам иттерде.

Бераздан соң «Кошлар» көенә теге кыз тагын җырлап җибәрде:

Төркемләнеп очкан аккошларның
Кара болыт юлын бикләгән.
Кайтыр иде безнең сөйгән ярлар,
Ләкин сугыш әле бетмәгән.

Әйе, сугыш бетмәгән шул әле. Сугышның бетүе өчен фашист бандитларны бөтенләй юк итәлүе кирәк. Ә моңа ирешү өчен сугыш кырында да, хезмәттә дә бүгенге кебек уңышларны тагын да арттырырга кирәк. Бәлки бу җырны җырлаган Сара иптәш Минһаҗова үзе дә шулай уйлыйдыр. Шуңа күрә дә ул көнлек норманы 200 әр процентка үтәп барадыр... Чөнки бу фикер—һәрбер хезмәт иясенең уртак фикере бит.

* * *

Киемнәрне чистарту бүлегенә кереп барганда, артельнең производство бүлеге мөдире Гыйззи иптәш Сабирова очрады.

— Безнең бабайларның, кызларның эшләве ошадымы?—дип сорады ул. — Менә стахановча эшләүче иптәшләрнең эш нәтиҗәләре белән танышыгыз,—дип үзенең дәфтәрендәге исемлекне күрсәтте.

Анда, көнлек норманы 330 процентка үтәп баручы Фәйрүзә Сафина, Миңсылу Әкбәрова, 200 әр процентка үтәүче Зәйнәп Баһаветдинова, Зәбидә Гыйлаҗова, Сара Галиуллина һәм 400 процентка үтәүче Шәфигулла Хисмәтуллин иптәшләр, барлыгы—46 исем язылган.

— Мондый иптәшләр хәзер артельдәге барлык эшчеләрнең 79 процентын тәшкил итә. Гомумән, норма үтәмәүче кешеләр бездә юк,—ди иптәш Сабирова.

Шунда ук ул алдынгы стахановчы Шәфигулла Хисмәтуллин турында сөйли башлады:

— Ул 72 яшьлек бабай инде. Үзенең 3 улы фронтта. Ул еш кына «минем тырыш хезмәтем дошманның тизрәк җиңелүен, ә газиз улларымның дан белән кайту көннәрен тизләтәчәк»,—ди.

Менә скорняк цехы. Монда да машиналар, җанга рәхәтлек биреп, тигез ритм белән әйләнәләр. Машиналар каршында—башларына ал, кызыл, яшел һәм сөт кебек ап-ак яулыклар бәйләгән, елмаючан ачык йөзле эшчән кызлар һәм күзлекле, ак сакаллы бабайлар... Алар машиналарны кызу рәвештә әйләндерәләр, төрле өлгеләргә үлчәп мех кисәләр, бүрекләр калыплыйлар, әвеннән кибеп чыккан бүрекләрнең калыпларын төшерәләр... Кием цехындагы кебек җыр тавышлары монда да тукталмый. Берсе башлаган җыр кайвакытта күмәк хорга әйләнеп китә.

— Бу цех кичәге заданиене 150 процентка үтәде,—ди иптәш Сабирова.—Кызлар эштә матур гына нәтиҗәләр бирәләр. Артель стахановчыларының 40 проценты чамасы шушы цехтагылар.

Артель правлениесенә килеп кердек. Биредә яшел яфраклы нәфис гөлләр арасында счет төймәсе тартып утыручы кызлардан башка, бары тик бер генә ир кеше бар. Ул да—ватан сугышы инвалиды, артельнең председателе Шәйхи иптәш Моратов.

Иптәш Моратов бу артельдә күптән түгел генә эшли башласа да, үзен танытып өлгерде инде. Күп еллар буена производство планын үти алмый килгән «Кызыл бүрекче» артеле хәзер планнарны, графикны системалы рәвештә арттырып үтәп килә. Артель ягу, яктырту материаллары белән һәм чимал белән яхшы тәэмин ителгән.

Үзенең җылы бүрекләре белән тылда да, фронтта да киң танылган бу артель эшчеләренең бүгенге уңышларны ныгытуларын, аларны алда тагын да арттыруларын телибез.

ГАЛИ ГАЛИЕВ,

Кукмара районы.

Язгы чәчүгә отлично әзерләнергә, терлекләрне тук һәм җылы кышлатырга!

Колхозларның һәм совхозларның сугышчан бурычы әнә шул

РЕМОНТЧЫЛАР ЙӨКЛӘМӘЛӘРЕН ҮТИЛӘР

(Кукмара МТС директоры иптәш Гәрәев белән беседа)

— Фронтларда Кызыл Армиябезнең уңышлары,—ди иптәш Гәрәев,—безнең МТС коллективында да чиксез зур рухлану тудырды. Эшчеләр радио аша бирелә торган хәбәрләрне түземсезлек белән көтеп алалар. Алар Кызыл Армиябезнең уңышларына үз постларында тагын да яхшырак эшләү белән, социалистик ярышны көннән-көн киңрәк җәелдерү белән җавап кайтарырга ашкыналар.

Тракторларга һәм аларга тагылма машиналарга ремонт ясаучылар, Кызыл Армиябезнең 25 еллыгы якынлашу уңае белән, хезмәт җитештерүчәнлеген күп тапкыр көчәйтәләр. Бу уңай белән алынган йөкләмәләр уңышлы үтәлә. Слесарьлардан Желебин һәм Газизуллин иптәшләр, трактор бригадасы бригадирларыннан Нургалиев һәм башка күп кенә иптәшләр ремонтта көнлек заданиеләрне һәркөнне 150—200 процентка үтәп киләләр.

Иптәш Бариев бригадасы Кызыл Армиянең 25 еллыгы көненә үзенең 3 данә «ЧТЗ» тракторларына ремонт ясауны тәгәлләргә йөкләмә алган иде. Бригада бу тракторларның икесенә ремонтны тәмамлады. Өченче тракторга да ремонт ясау бетеп килә.

Без төзәтелергә тиешле 56 тракторның 37 сен төзәттек инде. Бу эшне 15 нче марттан да соңга калмый тәгәлләү өчен барлык мөмкинлекләрдән файдаланабыз.

Тагылма машиналарга ремонт ясау да соңгы көннәрдә яхшы гына җанланды: 64 сабанның 30 ы, 31 чәчү машинасының 22 се, 37 культиваторның 15 е әзер инде.

„Алга" МТС ы ремонтны тәгәлләде

Ремонтчылар арасында социалистик ярышны киң җәелдерү, эчке мөмкинлекләрдән тулысынча файдалану нигезендә Мөслим районының Мөслим МТС ы тракторларга ремонт ясауны 1 нче февральгә үк тәмамлаган иде. Шул ук районның «Алга» МТС ы да аннан күп калышмады. Кичә «Кызыл Татарстан» редакциясенә «Алга» МТС ында да ремонтның 8 нче февральдә тәгәлләнүе турында хәбәр алынды.

Совхозны өзеклектән чыгарырга

ЧИСТАЙ, 10 февраль. **(Телефон буенча).** Чистайдагы Галактионов исемендәге совхозда, кышка әзерлекнең начар булуы нәтиҗәсендә, атлар бөтенләй ачык һавада торалар. Сыерлар һәм сарыклар өчен дә җылы урыннар юк. 60 бәрән алу көтелә. Алар өчен ярарлык урын әзерләү турында уйламыйлар да.

Сыерлар, сарыклар һәм атлар үз вакытында ашатылмыйлар. Хәтта икешәр көн буенча терлекләргә су бирелмәгән вакытлар да еш кына булгалый. Азык җитәрлек түгелме әллә? Юк, алай түгел. Киресенчә, совхозда азык бик күп: 1.100 тонна чамасы печән, бодай саламы, кибәк һәм башка азыклар бар. Тик аларны терлекләргә китереп ашатуны оештыру гына юк. Хәзерге көндә биредә терлекләргә көненә бары 4 әр килограмм исәбеннән яртылаш черек арыш саламы бирәләр.

Җылы урын булмау, ач тоту нәтиҗәсендә быел кышка кергәч, күп кенә сарыклар һәлак булган. Исән калганнарының да 20 процентының йоннары коелып беткән.

Атлар һәм дуңгызлар да бик начар хәлдә тотылалар.

Совхоз директоры Абрамовның коточкыч бу фактларга һич тә исе китми. Ул совхозда бөтенләй тормый дип әйтерлек, ара-тирә килеп кенә киткәли, һаман да Чистайда тора. Биредә зоотехник та, ветврач та һәм башка белгечләр дә бар. Алар да совхоздагы бу хәлләрне «күрмиләр».

Совхозның язгы чәчүгә әзерлеген әйткән дә юк инде. 25 тракторның һаман да әле 7 сенә генә, 20 чәчү машинасының 10 ына гына ремонт ясалган. Сабаннар, культиваторлар, тырмалар берсе дә ремонтка кертелмәгән. Ремонтта 37 кеше урынына бары 17 кеше эшли. Орлык чистарту тәгәлләнмәгән.

Хезмәт дисциплинасы соң дәрәҗәдә түбән. Хәтта прогул ясаучылар да бар. Ләкин Абрамов бу җинаятьләргә дә бик салкын карый. Прогул ясаучыларның берсе дә тиешле законнар тәртибендә җавапка тартылмаган.

Эшчеләр арасында политик-масса эшләре алып барылмый. Җыелышлар, производство киңәшмәләре үткәрелми. Зоотехника һәм агротехника түгәрәкләре оештырылмаган. Бу эшләр белән беренче чиратта политбүлек (начальнигы иптәш Смирнов) кызыксынырга тиеш иде. Ләкин иптәш Смирнов совхоздагы кимчелекләргә шаһит булып торудан ерак китә алганы юк.

Кыскасы, Галактионов исемендәге совхоз тирән өзеклектә. ВКП(б) ның Чистай райкомы бу совхозга җитди игътибар бирергә тиеш. Район прокуроры да, билгеле, совхоз белән кызыксынып.

Ш. ШАКИРОВ.

ФЕРМА АЛДЫНГЫЛАРЫ

«Беренче Май» колхозының (Тәкәнеш районы) терлекчелек фермасы районның алдынгы фермаларыннан санала. Ферма мөдире комсомолка иптәш Сафина үз эшен яратып эшләве нәтиҗәсендә күп кенә уңышларга ирешә. Иптәш Сафина ферма работниклары арасында агитация-масса эшләрен яхшы оештыруга бик нык әһәмият бирә. Ул аларны практик эш өстендә тәрбияли. Терлекләрне вакытында ашату, эчертү, чистарту һәм башкалар турында әледән-әле беседалар үткәрә. Шуның өчен дә фермада яхшы эшләүчеләрнең саны көннән-көн арта бара.

Менә иптәш Баһавиева. Ул 9 тана һәм сыерлар карый. Аларны вакытында ашата, вакытында эчертә. Абзарларны чиста һәм җылы тота. Ул карый торган сыерлар барысы да яхшы көрлектә.

Кызылармеец хатыны иптәш Нәҗипова 77 сарык тәрбияли. Ул эшкә килү белән иң элек аларны барлап чыга. Аннан соң ашата, эчертә, тораклары яхшылап чистарта. Иптәш Нәҗипова быел кыш 21 баш сарыктан 22 баш бәрән алды. Бәрәннәр барысы да исән-сау үсәләр. Аларның тораклары иркен, җылы һәм чиста.

— Ирем фронтта. Ул минем һәм балабызның бәхете өчен сугыша. Мин дә үз эшемне яратып башкарам. Кызыл Армиягә күбрәк ит бирү турында гына уйлыйм,—ди иптәш Нәҗипова.

Иптәш Вәлиева да калышмый. Ул 10 баш дуңгыз тәрбияли. Октябрь аенда гына әле колхоз правлениесе 4 әр, 5 әр килограмм авырлыгындагы дуңгыз балалары алган иде. Хәзер аларның авырлыклары 25—30 ар килограммга җитә.

Ф. ХӘМЗИН.

Рәсемдә: Н-че завод стахановчысы иптәш Леднева. Ул норманы 200 процентка үти.

С. Парфенов фотосы.

Фронтовикларга бәйрәм бүләкләре

Кызыл Армиянең 25 еллыгы уңае белән Казан шәһәренең промкооперация артельләре батыр сугышчыларга бүләкләр әзерлиләр. «Азат хатын» артеленең эшчеләре бүләк өчен 3.000 данә кисет, 1.000 пар мех бияләй, Татарстанның 20 еллыгы исемендәге артель эшчеләре кульъяулыклар, җылы чолгаулар, телогрейкалар, сырган чалбарлар тегәләр. «Химпром» артелендә 5.000 тартма теш порошогы, Октябрьның 15 еллыгы исемендәге артельдә 30.000 пачка шырпы әзерләнә.

* * *

Шәһәрнең Сталин районындагы пионерлар һәм мәктәп балалары героик сугышчыларга бәйрәм бүләкләре алып җибәрү өчен 38.000 сум акча туплап тапшырдылар. 12 нче мәктәптә укучылар 7.100 сум, 35 нче мәктәптә укучылар 7.000 сум бүләк иттеләр. Балалар фронтовикларга кисетләр һәм кульъяулыклар әзерлиләр.

* * *

Тәкәнеш районы, Никифоровка авылы колхозчылары Кызыл Армиянең 25 еллыгы уңае белән фронтовикларга җибәрү өчен бәйрәм бүләкләре әзерлиләр. Колхозчылар соңгы көннәрдә генә дә бүләк фондына 80 килограмм ит, 20 килограмм май, 40 килограмм суган, 10 пар бияләй һәм10 пар җылы оекбаш тапшырдылар.

М. ХӨСӘЕНОВ.

БӘЙРӘМ КӨННӘРЕНДӘ КОНЦЕРТЛАР

Татарстан дәүләт филармониясе Кызыл Армиянең 25 еллыгы уңае белән предприятиеләрдә, учреждениеләрдә, колхозларда һәм хәрби частьларда күп кенә концертлар үткәрергә билгеләде. Колхозларда концертлар бирү өчен 3 сәнгать бригадасы җибәрелә. Бригадаларда сәнгать мастерларыннан Исмәгыйль Һилалов, Фәйзи Биккинин, Сара Садыйкова иптәшләр һәм башкалар эшләячәкләр.

Татарстанның җыр һәм биюләр ансамбле бәйрәмгә карата махсус программа әзерләде. Программага Октябрь революциясенә кадәр булган һәм аннан соң чыккан халык җырлары, Бөек ватан сугышы чорында иҗат ителгән җырлар, классик композиторларның һәм совет композиторларының әсәрләре кертелде.

Комедия һәм эстрада ансамбльләре дә бәйрәм хөрмәтенә махсус программалар әзерләделәр.

ПАРОВОЗЛАР ОЗАК РЕМОНТЛАНАЛАР

Соңгы вакытта Казан тимер юлының бөтен эше Әгерҗе депосының эшенә бик нык бәйләнгән. Паровозларга ремонт сыйфатының түбән булуы, аларның юлда бозылулары нәтиҗәсендә фронт һәм тыл йөкләрен төягән поездлар хәрәкәтенә тоткарлык ясавы мөмкин.

Депо начальнигы иптәш Лисовскийның җебегәнлек күрсәтүе нәтиҗәсендә кайбер машинистлар күп вакытларын юлда түгел, депода паровозларына ремонт ясап үткәрәләр. Юлга чыгарга тиешле бригадалар локомотивларга ремонт ясап, 10—15 сәгать вакытларын әрәм уздыралар. Күптән түгел генә машинист иптәш Кучулов локомотивны 16 сәгатьтән артык ремонтлады. Зур тәҗрибәсе булган бу машинистның болай эшләвен бары тик эшкә салкын каравы белән генә аңлатырга мөмкин.

Өлкән машинист иптәш Карманников күптән түгел генә бер уңышсыз рейс ясады. Ул дүрт тәүлек эчендә бары тик 278 километр гына юл үтте. Паровоз пар һава насосының бозылуы аркасында юлда 117 сәгать ремонтта торды. Икенче рейста да Карманников начар эшләде, составны юлда калдырып, паровозны ремонтка туктатты.

Машинист Вагапов бригадасы поездны Әгерҗедән Бәдрәш станциясенә 60 сәгать алып барды.

Бу фактлар Әгерҗе бүлеге паровоз хуҗалыгында (начальнигы Прокофьев) һәм Әгерҗе депосында (начальнигы Лисовский) җитәкчелекнең йомшаклыгы турында сөйлиләр. Алар аерым машинистларның начар эшләүләренә килешүчәнлек күрсәтәләр, ялкауларга, дисциплина бозучыларга административ характерда чаралар күрмиләр.

Н. ГУСЕВ.



Дон буенда азат ителгән авылларның берсендә.

ТАСС фотохроникасы.

СОВЕТ ИНФОРМБЮРОСЫННАН

11 нче ФЕВРАЛЬДӘГЕ КИЧКЕ БЕЛДЕРҮ

11 нче февральдә **Украинада** безнең гаскәрләр **Лозовая** шәһәрен һәм тимер юл узелын алдылар.

Чугуевтан көньяктарак безнең гаскәрләр халык яши торган күп пунктларны, шул исәптән эшчеләр поселогы **Андреевканы**, тимер юл станциясе **Беляевканы** алдылар.

Новочеркасскидан төньяк-көнчыгыштарак безнең гаскәрләр, һөҗүмне дәвам иттереп, халык яши торган күп пунктларны, шул исәптән зур пунктлардан **Мечетнойны, Зайцевканы, Керчикны, Мелеховскаяны,** тимер юл станциясе **Богураевны** алдылар.

Фронтның башка участокларында безнең гаскәрләр элекке юнәлешләрдә сугышлар алып бардылар.

* * *

10 нчы февральдә безнең авиация частьлары фронтның төрле участокларында немецларның гаскәрләр һәм йөкләр төялгән 200 гә якын автомашинасын юк иттеләр яки зарарладылар, 15 артиллерия батареясының утын бастырдылар, бер тимер юл эшелонын җимерделәр, ике батальонга якын дошман пехотасын таркаттылар һәм бер өлешен юк иттеләр.

* * *

Ростов-Дон районында безнең гаскәрләр дошманга каршы каты сугышлар алып бардылар. Немецларның танклары һәм пехотасы бик каты каршылык күрсәтәләр, ләкин безнең сугышчыларның басымы астында үзләренең позицияләрен бер-бер артлы калдырып китәргә мәҗбүр булалар. Бер участокта безнең подразделениеләр бик каты сугышта гитлерчыларны зур югалтуларга дучар иттеләр, 7 орудие, 18 автомашина һәм башка трофейлар кулга төшерделәр. Икенче бер участокта дошманның берничә контратакасы кире кайтарылды. Немецларның 3 танкысы зарарланды һәм яндырылды.

* * *

Краматорская районында безнең гаскәрләр һөҗүм сугышлары алып бардылар. Дошман бу участокка бик күп мотопехота һәм танклар китереп, совет гаскәрләренең алга баруын тоткарларга маташа. Безнең сугышчылар гитлерчыларның күп санлы контратакаларын кире кайтардылар. Немецларның күп подразделениеләре бөтенләй юк ителде. Кечкенә генә бер участокта 600 дән артык дошман солдатлары һәм офицерлары кырып ташланды. Дошманның 6 танкысы, 4 орудиесе, 4 миномет батареясы юк ителде һәм 30 га якын ДЗОТы җимертелде.

Безнең очучылар дошманның бер аэродромына һөҗүм ясадылар һәм немецларның җирдә тора торган 28 самолетын юк иттеләр. Һава сугышларында дошманның 13 самолеты бәреп төшерелде.

* * *

Волчанск районында безнең гаскәрләр алга киттеләр һәм халык яши торган берничә пунктны алдылар. Н-че часть сугышчылары немецларның бер батальон пехотасын тар-мар иттеләр һәм танкка каршы ата торган 6 орудие, 14 пулемет, 41 автомат, бер ашлык склады һәм бер сугыш припаслары склады кулга төшерделәр. Өстәмә саннарга караганда, Белгород районында безнең частьлар кулына төшкән трофейлар арасында бер самолет, 10 танк, 17 паровоз, 8 тимер юл эшелоны, шулардан сугыш припаслары төялгән 2 эшелон, 10 сугыш припаслары склады бар. 1.000 гә якын дошман солдатлары һәм офицерлары плен алынды.

* * *

Курскидан төньяктарак безнең гаскәрләр һөҗүмне дәвам иттерделәр. Н-че часть сугышчылары немецларны көчле итеп ныгытылган позицияләрдән бәреп чыгардылар һәм бик күп трофейлар кулга төшерделәр. Немецларның бер бронепоезды юк ителде. Икенче бер участокта безнең подразделениеләр немецларның контратакасын кире кайтардылар һәм дошманның 200 гә якын солдат һәм офицерларын, 8 танкысын һәм 5 орудиесен юк иттеләр.

* * *

Ленинград өлкәсенең бер районында хәрәкәт итүче партизаннар отряды дошманның бер сугыш припаслары складын шартлаткан. Совет патриотлары немецларның волость управаларына һөҗүм ясаганнар һәм 160 немец солдатын һәм офицерын юк иткәннәр. Бик күп трофейлар кулга төшерелгән. Бу отрядның партизаннары бер ай эчендә немецларның 7 хәрби эшелонын юлдан чыгарганнар. Һәлакәт нәтиҗәсендә 7 паровоз һәм 64 вагон җимерелгән.

* * *

Краснодар краеның Белореченская станицасыннан качар алдыннан гитлерчылар гражданнар халкын кан коеп җәзалаганнар. Белая елгасы янында немецлар станица халкыннан 100 дән артык кешене атканнар. Үтерелүчеләр арасында май заводы эшчесе Прасковья Степкина, эшче Букарев, колхозчы Ксения Молдавская һәм башкалар бар. Фашист кабахәтләр бер группа совет хәрби пленныйларын һәм гражданнарын бер сарайга куып керткәннәр һәм шунда тере көе яндырганнар. Немец бандитлар тимер юлчыларның 34 йортын, урта мәктәпне, клубны, амбулаторияне, бала тудыру йортын, балалар бакчасын, ясләне, электр станциясен һәм станицадагы башка күп биналарны яндырып киткәннәр.

* * *

Франция патриотлары немец-фашист оккупантларга каршы аяусыз көрәш алып баралар. Лилльдә азат укчылар немец офицерлары ресторанына бомба ташлаганнар. Шартлау нәтиҗәсендә 23 гитлерчы үлгән һәм яраланган. Кароэнда азат укчылар 3 немец солдатын постта торганда үтергәннәр. Парижда патриотлар немецлар гаражына барып кергәннәр, андагы автомашиналарга бензин сипкәннәр һәм гаражга ут төрткәннәр. Немец солдатлары ашап утырган вакытта ашханәләргә гранаталар ыргытканнар. Гитлерчылар арасыннан күп кешеләр үлгән һәм яраланган.

БАТЫР СУГЫШЧЫЛАРГА ҖЫЛЫ КИЕМНӘР

Шәһәрнең Сталин районы хезмәт ияләре героик сугышчыларга җылы киемнәр туплауда зур активлык күрсәтәләр. Алар көз көнендә 8.000 данәдән артык төрле җылы киемнәр бүләк иткәннәр иде. Соңгы вакытта район складына яңадан 63 данә кыска тун, 223 пар киез итек, 873 пар җылы бияләй, 45 пар телогрейка белән сырган чалбар һәм башка киемнәр тапшырылды.

Нефтесбыт, Россовхозснаб конторасы работниклары, «Обувщик» артеле членнары бу эштә гүзәл үрнәкләр күрсәтәләр. Алар соңгы көннәрдә күп кенә кыска туннар, җылы бияләйләр һәм сырган чалбарлар бүләк иттеләр.

АНГЛИЯНЕҢ СССР ДАГЫ ИЛЧЕСЕ СӘР АРЧИБАЛЬД КЕРРНЫҢ ЧЫГЫШЫ

ЛОНДОН, 8 февраль. (ТАСС). Рейтер агентлыгының хәбәр итүенә караганда, Англиянең СССР дагы илчесе Арчибальд Керр (ул якын вакыт эчендә Москвага киләчәк) радио буенча чыгыш ясап, түбәндәгеләрне белдергән: «Нацистлар безнең күңелебезгә курку салу өмете белән большевизм шәүләсе дип аталган нәрсә турында лыгырдап, яңадан үзләренең иске хәйләләренә керештеләр. Моңа җавап бирү өчен инглизләрнең бик каты сүзләре бар, ләкин бу сүзләр дипломатия сүзлегенә кермиләр. Инглизләр белән руслар арасында дошманлык тудырырга немецларның маташулары барып чыкмаячак, чөнки Англия халкы Кызыл Армиянең искиткеч уңышларына ихтирамнан һәм сокланудан да зуррак тойгыларны кичерә. Англия халкы тыныч вакытта да, шулай ук сугыш вакытында да руслар белән бергә хезмәттәшлек итүгә тирән теләкне, хәтта дөресрәге, шуңа карар биргәнлекне күрсәтә. Үткән елны кул куелган договор ике хөкүмәтнең тик тантаналы йөкләмәсе булып калмый, бәлки ике халык арасында кешеләрчә төзелгән договор булып тора. Без үз тарафыбыздан бу договорны эшкә ашырырга омтылабыз. Үз чиратымда мин Советлар Союзында да бу договорга тулы көч бирергә омтылыш барлыкны күрдем. Без бер-беребезгә бик якын торабыз. Кемнең булса да безне аеруына без ирек бирмәячәкбез.

Аданада булган сөйләшүләр турында Төркия матбугаты

ИСТАМБУЛ, 10 февраль. (ТАСС). Соңгы көннәрдә Төркия газеталары Черчилльнең Аданада булган сөйләшүләре турында мәкаләләр белән чыктылар. «Улус» газетасы Аданада булган сөйләшүләрнең бик әһәмиятле булганлыгын күрсәтеп үтә. Газета болай дип яза: «Һичшиксез, Англиянең җаваплы җитәкчесе союзникларның халыкара вакыйгаларга ничек карауларын Төркия делегациясенә аңлатып бирде һәм Төркиянең позициясе турында Төркия делегациясеннән ачык җавап алды. Бу яктан караганда Аданада булган очрашу Төркия—Англия союзының бик гүзәл нәтиҗәсе булып калыр».

Газета Төркиянең һәм Британиянең дәүләт эшлеклеләренең сөйләшүләр вакытында Европадагы һәм бигрәк тә турыдан-туры Төркия кызыксына торган районнардагы хәлне җентекләп тикшергәнлекләрен һәм төп мәсьәләләрдә үзләренең карашлары бердәм икәнлекне белдергәнлекләрен яза. Газетаның әйтүенчә, Адана сөйләшүләре вакытында Төркиянең тынычлыгын саклау турындагы мәсьәлә каралган.

«Икъдам» газетасы редакторы Даверның фикеренчә, Черчилльнең Касабланкада Рузвельт белән булган очрашуы артыннан ук үткән Адана сөйләшүләре, Англия—Төркия дуслыгын гына түгел, бәлки Төркия белән Америка Кушма Штатлары арасындагы дуслыкны да ныгытачак. Газета болай ди: «Төркия белән безнең союзнигыбызның бу союзнигы арасындагы өзкерсез элемтә һәм дуслык шул кадәр нык ки, ул союз белән бер дәрәҗәдә».

ТӨНЬЯК АФРИКАДА СУГЫШ ХӘРӘКӘТЛӘРЕ

ЛОНДОН, 10 февраль. (ТАСС). Рейтер агентлыгы Роммель гаскәрләренең хәзер Триполитаниядән бөтенләй кысрыклап чыгарылганлыкларын һәм Тунис чигеннән теге якта торуларын хәбәр итә.

Союзникларның Төньяк Африкадагы көчләре штабының чираттагы белдерүендә союзникларның авыр бомбардировщикларының Суска атака ясаганлыклары һәм анда бомбалар төшүдән дошманның 2 пароходы зарарланганлыгы әйтелә.

Франциянең Төньяк Африкадагы көчләре штабының белдерүендә әйтелүенчә, бөтен Тунис фронтында патрульләрнең хәрәкәтләре булган. Дошман танкларының Гафстан көнчыгыштарак союзниклар позицияләренә каршы разведка атакасы дошман өчен югалтулар белән кире кайтарылган.

ЛОНДОНДА ҺАВА ТРЕВОГАСЫ

ЛОНДОН, 10 февраль. (ТАСС). Рейтер агентлыгының хәбәр итүенчә, бүген төштән соң Лондонда аз гына вакытка һава тревогасы игълан ителгән.

Японнар Гвадалканарны калдырып киткәннәр

ТОКИО, 10 февраль. (ТАСС). Домей Цусин агентлыгының хәбәр итүенә караганда, Японияның короллы көчләренең Яңа Гвинеядагы Буналы һәм Соломон атауларындагы Гвадалканар атавын эвакуацияләгәнлекләрен Япониянең хәрби командованиесе рәсми рәвештә игълан иткән.

БЕЛДЕРҮ

Бүген, иртәнге 11 сәгатьтә шәһәр советы башкарма комитеты бинасында шәһәрнең гадәттән тыш комиссиясенең утырышы була. Көн тәртибе: «Шәһәрне чистарту һәм йогышлы авыруларга каршы көрәш».

Утырышка район башкарма комитетларының председательләре, сәламәтлек саклау бүлекләренең һәм райкомхозларның, район торак йортлары идарәләренең мөдирләре, милиция начальниклары, ДСИ начальниклары һәм вузларның директорлары килергә тиешләр.

Җаваплы редактор урынбасары **ГАЛИМ РЯБКОВ.**

12 нче февраль, 15 сәгатьтә гомуми һәм анорганик химия институты китапханәсе бинасында (Чернышевский урамы, 18, Бутлеров корпусы, 2 нче кат) СССР Фәннәр Академиясе химия институтының гыйльми советы утырышында В. И. Горемыкин тарафыннан химия фәннәре докторы дигән гыйльми дәрәҗә алу өчен

диссертация яклау була.

Тема: „Платинаның һәм палладийның гидроксиламин һәм гидразин берләшмәләре“. Рәсми оппонентлар: академик В. Г. Хлопин, химия фәннәре докторы, профессор А. А. Гринберг һәм химия фәннәре докторы, профессор Н. К. Пшеницын. Диссертация материаллары белән институт китапханәсендә танышырга мөмкин.
49-1-1

ШӘҺӘРНЕҢ БАРЛЫК ОЕШМАЛАРЫНА БЕЛДЕРЕЛӘ:
алар штатларын теркәтү мәсьәләләре буенча үзләре эшли торган районнардагы район финанс бүлекләренә мөрәҗәгать итәргә тиешләр.
48-1-1

Театрларда һәм киноларда

Татар дәүләт опера һәм балет театры. Бүген — „*Евгений Онегин*“. 13 нче февральдә — „*Ильдар*“.

Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры. 14 нче февральдә көндез һәм кич—„*Габбас Галин*“.

Зур драма театры. Бүген — „*Испан священнигы*“. 13 нче февральдә—„*Маскарад*“.

Дәүләт циркы. Бүген—зур цирк тамашасы һәм французча көрәш ярышлары. Кич 8 сәгатьтә башлана.

„Электро“ — музыкаль комедия „*Антоша Рыбкин*“.

„Унион“—„*Котовский*“.

„Пионер“—көндез һәм кич — „*Корыч ничек чыныкты*“.

„Чатки“—„*Өч мушкетер*“.

„Кызыл йолдыз“—„*Райком секретаре*“.

Редакциянең телефон номерлары: җаваплы редактор—АТС 73—27, редактор урынбасары—АТС 76—29. секретарь—АТС 79—29. Партия тормышы бүлеге 14—75, промышленность-транспорт һәм хатлар бүлеге АТС 75—55, авыл хуҗалыгы бүлеге АТС 76—14, типография 36—60.

ПФ 142 «КРАСНАЯ ТАТАРИЯ» һәм «КЫЗЫЛ ТАТАРСТАН» издательствосының АЛЕКСАНДРОВ ИСЕМЕНДӘГЕ ТИПОГРАФ ИЯСЕ № Заказ 240